Казан (Идел буе) федераль университеты
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты
Габдулла Тукай исемендәге
татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге



# Раушан

## Студентлар газетасы

№9/25.12.2014

### Милли моң бәйгеләре

Кая гына барсак та, кайда гына яшәсәк тә, безне татар моңы йокыдан уята, озата, ул безне уйландыра, юксындыра, юата. “Милли моң – ул әсәрнең жаны”, – дигән Хәсән Сарьян. Бу моң Бөтенроссия “Илһамлы каләм” һәм “Шигъри Сабантуй” әдәби әсәрләр конкурсында катнашучыларның хикәя-язмаларында, шигырь-нәсерләрендә чагылыш тапкан иде.

24 нче ноябрь көнне Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге Татарстан районнарыннан тыш, Башкортстан, Пермь, Киров өлкәсеннән һәм Чувашиядән килгән мәктәп укучылары һәм укытучыларын үзләрендә кунак итеп җибәрде. Бу көнне “Илһамлы каләм” һәм “Шигъри Сабантуй” бәйгеләренең йомгаклау тантанасы булды. Әлеге тантанада бәйгедә икенче турга үткән укучылар катнашты.

“Илһамлы каләм” һәм “Шигъри Сабантуй” бәйгеләренә эшләр 1 нче марттан 31 нче октябрьгә кадәр кабул ителде. “Шигъри сабантуй”га шигърият буенча эшләр килсә, “Илһамлы каләм”гә проза, драматургия һәм публицистика буенча эшләр кабул ителде. Бу ике бәйгедә катнашкан әсәрләргә бәя бирү өчен, танылган шагыйрь һәм язучылар, галим-укытучылардан торган мәртәбәле жюри эшләде.

“Шигъри Сабантуй” бәйгесе буенча дүрт кызыксындыру бүләге, укучылар арасында “Яшь батыр” һәм студентлар арасында “Сабантуй батыры” номинацияләре каралган иде. “Яшь батыр” исеменә Теләче районы Баландыш урта мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы Тимербайев Илсаф Фидаил улы, ә “Сабантуй батыры” исеменә татар филологиясенең 4 нче курс студенты Хәбибуллина Ләйлә Фаяз кызы лаек булды.

“Илһамлы каләм”нең иҗат мәйданы исә тагын да киң. Анда проза, публицистика, драма буенча 9-11 нче сыйныф укучылары көч сынашты. Җиңүчеләр дә әлеге номинацияләр буенча билгеләнде. Моннан кала конкурс нигезендә махсус дүрт номинация дә каралган иде. Проза буенча 1 нче урынны Казан шәһәре 7 нче номерлы лицей-интернатының 10 сыйныф укучысы Насыйбуллин Булат яулады. Публицистикада беренчелекне Сарман районы Сарман гимназиясенең 10 нчы сыйныф укучысы Нәгыймова Гөлинә алды, ә драма өлкәсендә Чирмешән районы Лашман урта мәктәбенең 11 нче сыйныф укучысы Галимова Алсинәнең пьесасы беренчелеккә лаек дип табылды.

Һәрбер җиңүчегә дә мөхтәрәм жюри әгъзалары истәлекле бүләкләр, укытучыларына рәхмәт хатлары тапшырды. Катнашучыларның һәммәсенә катнашу таныклыгы бирелде. Бәйрәм тантанасы җыр һәм шигырьләр белән үрелеп барды.

Әлеге бәйгеләргә җаваплы филология фәннәре докторы Ләйлә Ихсан кызы Минһаҗева һәм филология фәннәре кандидаты, доцент Халисә Хатыйп кызы Кузьмина тарафыннан зур эш эшләнелде. Ләйлә Ихсановна тарафыннан укучы-укытучыларга әйтелгән үгет-нәсыйхәт һәм теләкләр бәйгеләрнең киләчәге булачагына этәргеч ясады. Бу күркәм чараларны тормышка ашыручыларга зур рәхмәтләребезне җиткерәбез!

“Илһамлы каләм” һәм “Шигъри Сабантуй” - ул учак! Киләчәктә дә бәйгене оештыручыларның тырыш хезмәте, катнашучылар белән даими элемтәсе әлеге ялкынны сүрелдермәс.

Эльвина Нәҗипова,
татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар
бүлегенең студентлар деканы

### Булганы җитәме?



Стипендия сүзен ишетүгә, һәр студентның күзләре очкынланып яна башлый, күңелләре җилкенәдер, мөгаен. Зур булмаса да, стипендия студентларның матди таянычы булып тора. Ә беренче стипендия алу аерым игътибарга лаек, чөнки ул беренче хезмәт хакы кебек, шундый кадерле һәм көтеп алынган була.

Беркөн дәрестә сүз арасында стипендия турында сөйләштек. Укытучы абый “Беренче стипендиягезгә нәрсә алдыгыз соң?” - дип кызыксынды. Миңа бу шулай ук кызык тоелды, һәм мин группадашларымның җавапларын зур игътибар белән тыңлап тора башладым. Тик серне ачарга теләмичәме, әллә оялыпмы, группадашларым уен-көлке белән генә җавап бирделәр: “кара көнгә” саклыйлар, янәсе. Озак уйлап тормадык, дус кызым белән, үзебезне чын журналистлар итеп хис итеп, беренче курс студентларыннан бу турыда сорашып чыгарга булдык.

Сораштыру нәтиҗәсе күрсәткәнчә, безнең студентларыбызның күбесе стипендияләрен әле алмаган. Стипендияләрен сарыф итеп бетерүчеләрнең күпчелеге яшәү кирәк-яраклары, кием-салым, телефон кебек әйберләр алганнар. Егетләр плеер ише әйберләр алсалар, кызлар кием-салымга өстенлек биргәннәр.

Без шулай ук студентларның стипендия күләменә мөнәсәбәтен сорашмыйча булдыра алмадык. Акча бик четерекле мәсьәлә бит ул. Шунлыктан студентлар, артык сүз әйтмичә генә: “Безгә җитә, булганын түләп торсалар да бик шәп!” – дип җавап бирделәр.

Студент еллары – юкны бар итеп яши торган булса да, күңелле һәм онытылмас вакыт. Сораштыруыбызның азагында шундый нәтиҗәгә килдек: студент өчен стипендиянең күпме булуы мөһим түгел, күңел байлыгы һәм белемнәренең тирәнлеге мөһим! Ә сез ничек уйлыйсыз?

**Илүзә Гайфуллина, Алсу Замалеева, 1 нче курс студентлары**

### Киләчәгем хәл ителә... Нишләргә?!

11 нче сыйныф... Бигрәк җаваплы ел да соң. Имтиханнар, чыгарылыш кичәсе, киләчәк тормышыңны хәл итү турындагы мәсьәләләр. Болар барысы да безнең алдыбызга яшен тизлеге белән килә дә баса.

Уйла башым, уйла, уйла... Кая барырсың? Уйла! Киләчәгем хәл ителә бит!..

Хыялым - Казан федераль университетына укырга керү. Төгәлрәк әйтсәм, филология һәм мәдәниятара багланышлар институты. Хыял дип әйтүем бик үк дөрес тә түгел. Максат итеп куйдым мин аны үз алдыма. Максатыма ирешергә язсын иде!

Көн саен БДИ, БДИ дип исебезгә төшереп торучы укытучыларга рәхмәт. Тиздән аларны да язарбыз. Менә шуннан соң башлана башлар: документларны тапшыру, нәтиҗәләрне көтү...

Мин хәзерге вакытта ук үземне Казан федераль университетының абитуриенты дип атарга тулы хокуклымын дип саныйм. “Ачык ишекләр көне”н дә калдырмаска тырышам, чөнки нәкъ менә анда без үзебезгә кирәкле мәгълүматны ала алабыз. Имтиханнарга да мин бик ныклап әзерләнәм, чөнки КФУ югары баллар таләп итә.

Әйе, мин әлегә абитуриент. Бу исемем белән горурланмый булмый. Абитуриент - димәк, булачак студент.

Мәктәпне тәмамладым дип, бер дә борчыласы юк икән. Алда әле студент еллары! Ә студент елларын тиешенчә үткәрү өчен көч, дәрт ташып тора бездә.

**Мөхәммәдиев Рүзәл,**
**Балтач районы, Салавыч авылынын күппрофильле лицееның 11 нче сыйныф укучысы**




### Эх, егетләр!..

Татар филологиясе бүлегенә укырга килгән егетләрне санау өчен, елның елында кул бармаклары да җитә. Әлеге егетләрнең бу бүлеккә керүләре еш кына сораулар тудырса да (“Әй, егет, берүзең 29 кыз арасында нишләп йөрисең соң син? Әйдә, безгә күч!”), алар батырларча барлык курсны да укып, финишка кадәр барып җитәләр. Әлбәттә, күп кеше безне кызлар яраткан өчен генә монда килгән дип саныйдыр. Юк, һич тә алай түгел: без монда кызларны яраткан өчен түгел, ә кызларны күпләп яраткан өчен килдек!

Шушы бүлектә белем алу зур батырлык һәм көч тә сорый: парта ташулар, эскәмия күчерүләр, бер этаждан икенче этажга шкаф ташулар – барысы да “кадерле” егетне олы тормышка әзерли. Болар барысы да пүчтәк кенә... Сигезенче март бәйрәме белән чагыштырганда! Менә шушы көнне егетнең алдагы язмышы хәл ителә дә инде: укып бетерә алырмы ул биш елны, финансовый кризисы дипломнан иртәрәк ишегең шакымасмы?! Нәрсә генә дисәң дә, әлеге бүлектә укуның иң күңелле мизгелләре дә шушыдыр – үзеңнең төркемдәш кызларыңны сөендерү, чөнки аларның елмаюлары гына да күңелгә 29 төрле шатлык хисе өсти бит.

Безнең өчен күңелле мизгелләр бу уку йортында көн дә булып тора, аларның күбесе безнең якын дусларыбыз - кызларга бәйле. Минем теләгем мондый сезгә: киләчәктә дә бергә-бергә уңышларга ирешеп, зур җиңүләргә бергә атлыйк, кызлар!

**Ильяс Шаһиев,**
**3нче курс студенты**



# Без иҗатка гашыйкбыз



***Мин – Нәфыйкова Алия Азат кызы. Апас районы Каратун урта мәктәбендә белем алам. Татар теле, әдәбият фәннәрен яратам. Быел 11 нче сыйныфны тәмамлап, табиб һөнәрен үзләштерергә җыенам. Ике еллар чамасы шигырьләр язам, аңа кадәр зур сәхнәләрдә, чит автор әсәрләрен укып, урыннар яуладым. Киләчәктә кем генә булсам да, бу шөгылемне калдырмам дип ышанам.***

**Әтисенә ошаган кыз**
**Бәхетле була, диләр...**

Әткәй! Әткәй! Иң кадерле кешем,
Синең өстә бөтен авырлык.
Олы йөрәк Ходай бүләк иткән сиңа,
Китмәсен һич аннан батырлык.
Яннарымда син булганда гына
Җаннарыма тынлык урнаша.
Көчле җилкәң белән ышыклыйсың,
Шундый рәхәт синең кочакта!
Авырлыклар килеп туганда да
Бирешмәскә безне өйрәттең,
Мин кайгырып, хәлдән тайганда да
"Син көчле бит, кызым!"-дип әйттең.
Күңелемдә буран сизсәң әгәр,
Каршы тора алыр көч бирдең.
Мин бирешеп кабат егылганда
"Син ашыкма, кызым, түз!"-дидең.
Әтием, миңа синең киңәшләрең
Ныклы адымымның терәге.
Яныбызда бул син! Чынга ашсын
Йөрәгемнең шушы теләге.

**Иң зур теләк**
Өмет тулы күзләр белән
Карый һәр ятим бала.
Ни әйтергә тели соң ул,
Уйлары кая бара?
Уйлый микән ятим бала
Туган җире турында?
Җире түгел, гаиләсе
Микән аның уенда?!
Әйе, "Әнием" диеп тибә
Һәр баланың йөрәге.
Нигә кайбер балаларның
Юк икән соң терәге?!
Ник авыр тормыш сукмагын
Ул берүзе узачак?
Кем соң авыр минутларда
Ярдәм кулы сузачак?!
Әти-әни кирәк аңа!
Җылы бер кочак кирәк!
"Аңлыйм, балам!"-дип
әйтерлек
Терәк кирәк – шул теләк!

* * *
Ап-ак карлар... Ап-ак кәгазь бите...
Яңа тормыш юрый берәүгә.
Ышандыра якты киләчәккә,
Алып кайтмам, - дия, - үткәнгә...
Соңгы еллар авыр үтте, беләм...
Күңелеңдә синең бар яра.
"Түзалмамын, җиңалмамын!"- дидең,
Тик бит үтте! Кара! Ул кала...
Син булдырдың! Сыгылмадың бит син!
Тынычлансын, зинһар, күңелең.
Алда сине бары бәхет көтәр,
Тик онытма... Җиңел түгелен...



***Мин Хәбибуллина Альмирә Фирдүс кызы. Апас районы Кече Күккүз авылында туганмын. Казан дәүләт медицина университетының 3 нче курсында белем алам. Иҗатка кечкенәдән гашыйкмын: җырларга яратам, шигырьләр язам. Сезнең игътибарыгызга мәктәптә укыганда язган шигырьләремне тәкъдим итәсем килә.***

**Апасым - туган ягым**

Горурланам бер дә юкка түгел,
Тау ягында туган урыным
Шәхесләрнең иң-иңнәрен биргән
Бай тарихлы – Апас районы.

Сөйләсәләр, әйдә сөйләсеннәр,
"Караңгы бу район!" дисеннәр,
Көнчеләрне үртәп, нурын сибә
Бездән чыккан көчле шәхесләр.

Күтәр башың, дустым, горур атла,
Җырла, әйдә, татар җырларын!
Без изелдек, ләкин тугры калдык,
Күтәр әйдә Җиңү байрагын.

Татар теле – минем туган телем,
Апас ягы – минем туган җир.
Телем, җирем алда барсын, диеп
Гомерен биргән Җамал Вәлиди.

Апас, балкы, әйдә, атла алга!
Синдә туган ул һәм кызларың
Татар халык данын яклый бүген-
Мәңге сүнмәс алар даннары!

***
Күптән инде, кулга каләм алып,
Муенсадай тезеп уйларны,
Сүзләрнең дә иң кайнарын сайлап,
Язмаганга шигъри юлларны...

Күңелләрдә хисләр буранымы,
Яки уйлар шулай чуарлы?
Вакыт тапмый, йөрәгемдә генә
Язмый йөртәм серле уйларны.

Күзләр килде, кара бөркет булып,
Кошлар китте җылы якларга.
Бер моңсулык күңел түрен басып,
Алып китте әллә кайларга.

Салкын кыш та җитте, карлар яуды,
Бар җиһанда чиста, саф һава.
Тирә-якның күркен тасвирларга
Рөхсәт бирми ниләр соң миңа?!

...Менә шулай, бик күптәннән инде
Тотканым юк асыл каләмне.
Язалмыйча йөрим әллә нигә
Күңелдәге тирән уйларны...



***Таныш булыйк: мин - Гайфетдинова Диләрә Рифат кызы булам. Татарстан Республикасы Балтач районы Чутай авылында 1998 елның 3 нче июлендә туганмын. Әти-әниемнең көтеп алган беренче баласы мин. Алар миңа Диләрә исеме кушканнар. Диләрә исеме "яраткан, күңелне сөендерүче" дигән мәгънәне аңлата.***

***2005 нче елның 1 нче сентябрендә Чутай урта мәктәбенең 1 нче сыйныфына укырга кердем. Бүгенге көндә Нөнәгәр ГУБ мәктәбенең 10 сыйныфында белем алам. Мин биергә, спорт белән шөгыльләнергә, күңел ачарга, хыялланырга бик яратам. Шундый мизгелләрдә иҗат белән шөгыльләнәм. Шигырьләр, мәкаләләр язам. Иҗатым вакытлы матбугатта да еш басыла. Мәктәбебездә оештырылган иҗат түгәрәгенә йөрим. Без сыйныфташларыбыз белән кызыклы, күңелле, мавыктыргыч сыйныф бәйрәмнәре оештырабыз. Сыйныфыбыз бик тату һәм тырыш. Газета-журналлар укырга яратам. Кызыксынучанлык үземне дә илһамланырга этәрә. Мин мәктәптә татар теле, әдәбият, тарих, биология фәннәре белән кызыксынам.Тырышлыгым, ихтыярым быел мине җиңүгә дә китерде. Татар теле олимпиадасыннан район буенча беренче урынны алдым. Район күләмендә үткәрелә торган «Алтын каләм» конкурсында һәр елны катнашып, призлы урыннар яулыйм.***

***
Офык читләреннән әкрен генә,
Матур булып синдә таң ата.
Урамнардан узган көтүләрең
Хезмәт көнен һәркөн уята.
Иртүк торып, әгәр кырга чыксаң,
Ишетәсең тургай моңнарын.
Ишетәсең бодай, арышларның
Иртәнге саф җилдә шаулавын.
Әнә, кара! Барлык игеннәр дә
Елмаялар кояш ягына.
Кем сокланмас шушы матурлыкка
Ия булган туган ягыма!

**Туган нигез**
Кичке урам буйлап кайтып киләм,
Тәрәзләрдә утлар кабынган.
Кар көртләре күрәлмәгән өйләр
Мәңгелеккә инде ябылган.

Кешеләре, бәлки, исәндер дә,
Тик яшәми туган нигездә.
Бәхет эзләп читкә китүчеләр,
Кайтмый кире туган нигезгә.

Кичке авыл буйлап кайтып киләм,
Санап, барлап ятим йортларны.
Авылларны тотып тора әле
Бетермичә бары карт-коры.

Күпне күргән безнең өлкән буын
Иске кием кигән “яңартып”.
Яши алар тере тарих булып,
Туган җирне сөеп, яратып.

Көне-төне ачлы-туклы эшләп,
Авырлыкка түзгән, кыенга.
Бөгелеп тә, сыгылмаган өчен
Рәхмәт яусын өлкән буынга.

Рәхмәт яусын, әле ярый алар
Тотып тора мескен авылны
Алар барга яши әле авыл
Күпме генә күрсә авырны.

Килер бер көн - бәлки бик тиз булыр
Кадакланган такта алыныр,
Мәңгелеккә диеп киткән йортка
Янә кайтыр алмаш яшь буын.

Баш мөхәррир – Халисә Ширмән, Мөхәррир – Дамир Хөснетдинов
Иҗат коллективы: Гайфуллина Илүзә, Җамалиева Алсу
Биткә салу һәм дизайн буенча белгече – Диләрә Шакирова
Редакциянең фикере авторларның фикере белән туры килмәскә мөмкин.
Газетаны гамәлгә куючы Казан (Идел буе) федераль университеты
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты
Г. Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге
Редакция адресы: 420021, Татарстан ур., 2 , 108 бүлмә.
Хәбәрләшү өчен телефон: 89600447326 Электрон почта: rauschantat@yandex.ru